РАСЛЫЙМ

Россия ислам институты ректоры

Р.М. Мөхәммәтшин

______________________

РАСЛЫЙМ

Татарстан Республикасы Мөфтие

К.И. Сәмигуллин

______________________

# Татар теле, әдәбияты һәм татар халкы тарихы буенча дини уку йортлары студентлары арасында республикакүләм олимпиаданың нигезләмәсе

## 1. Олимпиаданың гомуми нигезләре

1.1. Татар теле, әдәбияты һәм татар халкы тарихыннан республикакүләм олимпиада Татарстан урта һөнәри һәм югары мөселман уку йортлары студентлары арасында Россия ислам институты һәм Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы Диния нәзарәте инициативасы һәм ярдәме белән «2021 нче ел – Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы» кысаларында уздырыла.

1.2. Олимпиада татар телен, әдәбиятын һәм татар халкы тарихын өйрәнү, саклау һәм үстерү өчен өстәмә шартлар тудыру, яшь буында телне өйрәнүгә кызыксыну уяту, татар мәдәниятенә хөрмәт тәрбияләү, тел һәм сөйләм культурасын камилләштерүне күздә тотып уздырыла.

1.3. Олимпиаданың максатлары:

- студентларда телне өйрәнүгә кызыксыну уяту, аңа хөрмәт тәрбияләү, милли үзаң формалаштыруга ярдәм итү;
- талантлы яшьләрне барлау;
- татар телен, әдәбиятын һәм татар халкы тарихын өйрәнүне пропагандалау;
- студентларны эзләнү-тикшеренү эшенә тарту.

1.4. Олимпиадада Татарстан Республикасы урта һөнәри һәм югары мөселман уку йортларында белем алучы 25 яшькә кадәрге студентлар катнаша ала.

1.5. Олимпиаданы оештыручылар: Россия ислам институты, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы Диния нәзарәте.

## 2. Олимпиаданы оештыру һәм уздыру

2.1. Олимпиада өч юнәлештә бер турда уздырыла: татар теле, татар әдәбияты һәм татар халкы тарихы.

2.2. **Татар теленнән олимпиада** язма формада үткәрелә. Ул тесттан һәм аерым биремнәрдән гыйбарәт.

2.2.1. Тест үз эченә фонетика, лексикология, морфология, синтаксис һәм пунктуациягә кагылышлы сорауларны ала һәм студентларның теоретик белемнәрен, аларны практикада куллана белү дәрәҗәсен ачыклауны максат итеп куя.

2.2.2. Биремнәр студентның язма сөйләм мөмкинлекләрен, байлыгын, сөйләмнең эзлеклелеген, аңлаешлылыгын ачыклауны күздә тота.

2.2.3. Тест һәм биремнәр эшләүгә 2 сәгать вакыт бирелә.

2.3. **Татар әдәбиятыннан олимпиада** үз эченә борынгы чордан алып бүгенге көнгә кадәр язылган әдәби мирасны ала.

Олимпиада ике өлештән тора: татар әдәбиятыннан эзләнү-тикшеренү эшен яклау һәм вәгазь сөйләү.

2.3.1. Татар әдәбиятыннан эзләнү-тикшеренү эшенең гомуми юнәлеше – «Татар әдәбияты һәм дин». Әлеге юнәлеш кысаларында һәр автор темасын үзе конкретлаштыра. Тикшеренү объекты буларак, татар язучылары (шагыйрьләре, драматурглары) иҗатында дин һәм әхлак мәсьәләләре, татар әдәбиятында дини мотивлар һ.б. алынырга мөмкин.

2.3.2. Эзләнү-тикшеренү эшенең күләме 20 биттән артмаска тиеш. Хезмәт, 2021 нче елның 1 нче апреленнән дә соңга калмыйча, **riitatkafedra@mail.ru** электрон адресына җибәрелә. Олимпиада вакытында катнашучылар үзләренең эшләре буенча 5-7 минутлык чыгышлар ясыйлар, жюри әгъзаларының сорауларына җавап бирәләр.

2.3.3. Олимпиаданың икенче өлешендә студентлар алдан әзерләнгән вәгазьләрен сөйлиләр. Вәгазь темасы – ирекле. Чыгыш өчен 10 минут вакыт каралган.

2.4. **Татар халкы тарихыннан олимпиада** тесттан һәм чыганаклар белән эшләүне күздә тоткан аерым биремнәрдән гыйбарәт.

2.4.1. Олимпиада язмача уздырыла, тест һәм биремнәрне эшләүгә 2 сәгать вакыт бирелә.

2.5. Олимпиадада урта һөнәри уку йортларыннан һәр номинациядә – берәр, югары уку йортларыннан өч студентка кадәр катнаша ала.

Әлеге чарада катнашу өчен, кушымтада күрсәтелгән форманы тутырып, **2021 нче елның 1 нче апреленә кадәр <u>riitatkafedra@mail.ru</u>** адресына җибәрергә кирәк.

2.6. Олимпиаданы оештыру һәм уздыру өчен махсус комиссия, эш группасы, жюри төзелә. Жюри һәр төркемдә җиңүчеләрне һәм призлы урын алучыларны билгели.

2.7. Олимпиаданы оештыру программасы Россия ислам институты, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы Диния нәзарәте тарафыннан раслана.

2.8. Олимпиадада катнашучыларның, аны оештыручы һәм уздыручыларның, жюри әгъзаларының битлекләрдән булуы, санитария һәм гигиена кагыйдәләрен үтәүләре таләп ителә.

2.9. Олимпиаданың уздырылу вакытын, урынын оештыручылар билгели һәм хәбәр итә.

## 3. Олимпиаданың нәтиҗәләрен ясау

3.1. Җиңүчеләр, призлы урын алучылар олимпиада нәтиҗәләре нигезендә, һәр өч юнәлештә аерым билгеләнә.

3.2. Җиңүчеләр, призлы урын алучыларга истәлекле бүләкләр тапшырыла. Һәр катнашучыга сертификат бирелә.

## 4. Олимпиаданы финанслау

4.1. Олимпиада Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы Диния нәзарәте бюджеты һәм Россия Федерациясе кануннары белән тыелмаган башка чыганаклар хисабына финанслана.

**Кушымта**

| Уку йорты | Юнәлеш | Фамилия, исем, әтисенең исеме | Телефон | Электрон адрес | Эзләнү-тикшеренү эшенең темасы (әдәбияттан) | Укытучы |
| --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |